Спектакль беткәч, сәхнә артына Уфаның күренекле зыялы тамашачылары, язучылары, шулар җөмләсендә Мәҗит ага Гафури кереп һәркайсыбызның кулларын кыстылар, кышкы сезонда Уфа халкын мәгънәви белем белән тәэмин иткәнебез өчен рәхмәтләрен әйттеләр.

Шулай иттереп, Уфа шәһәрендә алты айдан артык сузылган кышкы сезонда, атнасына бер-ике спектакль үткәреп, барлыгы кырыктан артык әсәр куйдык. Уфа халкы каршысында имтиханыбызны бирдек. (...)

«Тормыш» газетасында басылып барган тәнкыйть мәкаләләре безнең спектакльләребезнең уңышлы үтүләренә бик нык ярдәм иттеләр.

*(Л. Аитов истәлекләре беренче тапкыр «Казан утлары» (1966, № 7) журналында дөнья күргән һәм кыскартылып «С. Гыйззәтуллина-Волжская турында истәлекләр»./ Төз. Х. Гобәйдуллин. – Казан, 1982, (Б. 40–53) китабында бастырылган. Текст журналдан алынды.)*

***Касыйм Шамил[1]***

## Кадерле вә газиз туташыбыз

Татар сәхнәсенең беренче артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская турындагы язмамны

[1] *Касыйм Шамил (1892–1981)* – Татарстанның халык артисты. Татарстанның Октябрь районы Әлмәт авылында туа. Казанда Мәрҗани мәдрәсәсендә укыган чагында театр белән кызыксына башлый. 1910 елдан башлап «Сәйяр»да, 1914 елдан «Нур»да эшли. Бөек Октябрьдан соң К.Шамил Казанның елга аръягында (Пороховой бистәдә) беренче эшче театры оештыра. Беренче Татар дәүләт совет театрын төзүдә дә зур булышлык күрсәтә, 1920 елны «Сабанчы» исемле авыл театр труппасын оештыра, ә 1925 елны театр каршында балалар труппасын төзи. Аның сәхнә образлары бик күп. «Зәңгәр шәл»дә – Ишан, Әблиевнең «Шәмсекамәр»ендә – Суфи, «Банкрот»та – Сираҗи, «Башмагым»-да – Кәрим бай, «Яшенле яңгыр»да – Кулигин һ.б.



аның миңа 1914 елны үзе сөйләгән истәлегеннән башлап китәргә уйладым.

«1907 елның җәендә Кудашев-Ашказарский Оренбургтан Казанга килеп «Аркадия» бакчасында спектакль куйды[1]. Бу безнең өчен гаять тә зур вакыйга булганга, без – яшьләр – зур дәрт белән үзебезнең татар телендәге спектакльне карарга килдек. Ләкин көтеп алган минут җитеп, спектакль башлангач мин аптырап калдым. Нәрсә бу? Мөлаем тавышлы хатын-кызлар урынына, киенеп-ясанып чыккан калын тавышлы ирләр... Бу хәлгә тамашачыларның да ризасызлыгы сизелде. Спектакль бетеп, халык таралгач, без кызыксынып артистларның чыкканын көтә башладык. Ниһаять, кулына портфель тоткан Ашказарский күренде. Безне күрү белән: «Ну, чибәр кызлар, спектакль ошадымы?» – дип сүз башлады. Мин: «Юк, ошамады», – дидем. Шуннан ул елмаеп: «Башта таныш булыйк, туташлар», – дип кулын сузды. Без таныштык, ул безне озата барды. Без спектакль турындагы фикерләребезне әйткәч: «Кимчелегебез шунда, арабызда хатын-кызлар юк, менә сезнең шикелле матур туташлар безгә ярдәмгә килсә иде... Әгәр дә театрга артистка итеп чакырсам, ни диярсез? Сезнең арттан башкалар да килүе мөмкин, уйлап карагыз әле», – дип безне чын-чынлап димли башлады. Үземнең ул эшкә бик зур дәртем булса да, тиз генә җавап бирмәдем. «Кыз башым белән ялгыз читкә чыгып йөрү әллә ничек, менә әгәр аның белән бергә булганда», – дип янымдагы иптәш кызым Фатыйма Шаһимәрдановага карадым. Шул сүзне ишетүгә Ашказарский: «Менә күктән эзләгәнемне җирдән таптым», – дип кычкырып җибәрде һәм безне йортка кадәр озатып, иртәгә үк очрашырга вәгъдә куешып китеп барды...»

[1] *...«Аркадия» бакчасында спектакль куйды...* – Аркадия бакчасы. Ул вакытлардагы «Батан бакчасы», хәзерге «Ботанический сад» тирәсендәге бакча, дача урыннары.



Чыганак: Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская: әдәби нәфис, документаль, биографик җыентык / авт.-төз. Җ. Миңнуллин (фәнни мөх.); редкол.: И. Г. Әхмәтҗанов, Р. И. Вәлиев, Ф. М. Рәфыйков. – Казань: Җыен, 2012. – 479 б.: фоторәс. б-н. – (Шәхесләребез). – Библиогр.: б.465-474.

Татар театрының беренче артисткасы сәнгатькә иң тәүге адымын шулай искә ала иде. Сәхибҗамал Гыйззәтуллина яшь артистка буларак, тамашачылар игътибарын 1907 елда Мәкәрҗә ярминкәсе көннәрендә уйнаган спектакльләрдә үк үзенә җәлеп итә.

Бер спектакльдән соң тамашачылар артистларны кат-кат сәхнә алдына чакырып алкышлыйлар. Хәтта араларыннан берәү, хисләренә бирелеп китеп, сәхнәгә бүреген ыргыта. Бераздан әлеге егет бүрекне алырга сәхнә артына кергәч, «хәйлә» ачыла: аңа Ильяс Кудашев белән күрешеп сөйләшү өчен әнә шулай бер сылтау кирәк булган икән. Труппа Г. Камалның «Бәхетсез егет» әсәрен сәхнәгә куярга җыенган вакыт була бу. Рольләр күп, артистлар җитеп бетми. Шул вакыт әлеге «бүрек хуҗасы» килеп керә һәм үзен: «Уральскидан Камил Мотыйгыйның «Әлгасрелҗәдит» журналын таратырга дип ярминкәгә килгән шәкерт Габдулла Хәйруллин»[1], – дип таныштыра, артист буласы килү теләген аңлата.

«Бәхетсез егет» әсәренә рольләр бүлү башлана. Сәхибҗамал Гыйззәтуллина, хатын-кызлар роленә кеше җитмәвен истә тотып, бер кичтә өч роль уйнарга алына: беренче пәрдәдә – асрау кыз, икенче пәрдәдә – гимназистка, өченче пәрдәдә – бай малае Закирның сөяркәсе Гайни. Тамашачылар «Бәхетсез егет» спектаклен аеруча яратып карыйлар. Спектакльне күргән кешеләр сөйләвенчә, Сәхибҗамал Гыйззәтуллинаның өч рольне дә бер-берсенә һич охшатмыйча оста итеп башкарып чыгуы күпләрне таңга калдыра. Закир ролен – Мортазин, Кәрим байны театрга яңа кергән Габдулла Хәйруллин бик килешле уйныйлар.

Труппа акрынлап тулылана бара. «Сәйяр» артистлары тәвәккәлләп Кырым, Кавказ якларына юл

[1] ...*шәкерт Габдулла Хәйруллин*... – «Сәйяр» труппасының җитәкчесе һәм режиссёры, мәһшүр артист Габдулла Кариев театрга менә шулай килә.



тоталар. Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская үзенең истәлегендә: «Без анда данлыклы әзербайҗан артисты Хөсәен Араблинский[1] җитәкчелегендәге труппа белән бергә кушылып эшли башладык. Чөнки ул чакта әзербайҗан артистлары труппасында хатын-кызлар юк иде», – ди.

1908 елның июль аенда труппа бергәләп Әстерханга килә. Спектакльләрдә халык тулы була. «Надиршаһ» һәм «Бәхетсез егет»не уйныйлар. Закир ролен ярым татарча, ярым әзербайҗанча Араблинский уйный. Әстерхан халкына әзербайҗан халкы да, теле дә якын, таныш булганга бер дә гаҗәпләнмичә карыйлар.

Труппа тиздән Казанга кайта, «Новый клуб»[2] бинасында спектакльләр куя башлый. Бу вакытта мин дә театр белән кызыксына башлаган идем. Мәрҗани мәдрәсәсе шәкертләре белән «Мәдрәсә попечителе» дигән спектакльне дә уйнаган идек.

Труппа Казанда С.Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсә» дигән бер пәрдәлек комедиясен һәм Ярулла Вәлинең «Оят яки күз яше» исемле драмасын куйды. Мин төрле хәйләгә керешеп, кача-поса спектакльләрне карау бәхетенә ирешә идем. Билет алырга җай юк, минем мәдрәсәдән чыгып эш эзләп йөргән чаклар.

[1] ...*Хөсәен Араблинский җитәкчелегендәге труппа*... – Хөсәен Араблинский (Хәләфев, 1881–1919) – атаклы әзербайҗан театр эшлеклесе, артист һәм режиссёр.

«Сәйяр» Уральскидагы гастролен тәмамлап, Кырым, аннан Батум аша Тифлискә килә. Тифлистә Хөсәен Араблинский җитәкчелегендәге әзербайҗан труппасы белән очраша. Ике тугандаш халык вәкилләре – әзербайҗан һәм татар артистлары, көчлерәк коллектив булдыру өчен «Казан – Кавказ артистлары ширкәте» исемендә берләшәләр. Режиссёр итеп Х.Араблинский сайлана. Бу труппа үзенең чыгышын Ганҗә (Елизаветполь) шәһәрендә башлый. Аннан Нижний Новгородка килә, берләштерелгән гастроль 1908 елның август ахырларында тәмамлана.

[2] ...*«Новый клуб»*... – хәзерге вакытта Казанның Горький урамында К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма театры урнашкан бина.

Сәхибҗамал Гыйззәтуллинаның Казан тамашачысы каршында беренче чыгышлары булса да, халыкның игътибарын тәмам үзенә җәлеп итеп, зур алкышлар алганын хәтерлим. Тиздән Галиәсгар Камалның тәкъдиме буенча мин театрга эшкә кердем. Кариев миңа суфлерлык вазифасын тәкъдим итте.

1912–1913 еллар. «Сәйяр» труппасы белән гастрольгә киткән җирдән каты авырып Троицк шәһәр больницасына кереп калдым. Бер вакыт миңа Оренбургтан хат килде. Ул хат Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның мине үз труппасына чакырып язган хаты иде. Больницадан чыгу белән Оренбургка киттем. Сәхибҗамал Гыйззәтуллина мине ачык йөз белән каршы алды. Аларның кайбер артистлары солдатка каралу сәбәпле кешеләре җитми икән. Труппаның репертуарында «Җиңел хезмәттә», «Хөкемдә хаталык», С.Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» һ. б. әсәрләр бар иде.

Сәхибҗамал апа: «Мәкер вә мәхәббәт»не куярга бик ашкынып йөрсәм дә, ирләр составы аз булганлыктан куя алмыйм. Әсәрдәге Луиза ролен уйнау теләге миндә Казанда чакта ук туган иде инде. Ләкин уйнарга насыйп түгел әле», – диде.

1914–1915 еллар сезонын йомгаклаганда Оренбургта чыга торган «Вакыт» газетасында Кәбир Бәкернең безнең спектакльләрне шактый мактаган мәкаләсе чыкканы хәтердә. Аннары Уфада бераз уйнаганнан соң Чиләбегә киттек. Әмма ураза ае кергәнлектән, без анда спектакль куя алмадык. Артистлар вакытлыча кайсы кая таралдылар. Сәхибҗамал Гыйззәтуллина театрны бик якын күргән таныш Гариф Борнаевларда ял итәргә булды. Шәһәрдә моңа кадәр ак билет белән сугыштан калып торган кешеләргә мобилизация булу хәбәре таралды. Мин дә шундыйларның берсе булганлыктан, Борнаевның: «Син хәзер утыр да Кытай чигенә – Нурзайсанга кит, анда әле ак билетләрне тиз генә алмыйлар», – дигән киңәшен тотып, Нурзайсанга чыгып киттем.



Ләкин барыбер котыла алмадым. Омск шәһәрендә мине солдатка алдылар. Шәһәрдән читтә, бер солдат казармасында һичбер кешедән хәбәр ала алмый яттым. Тик кулымдагы «Вакыт» газетасыннан Кәбир Бәкернең мәкаләсен кат-кат укып кына хөрмәтле «Туташ»ны искә ала торган идем. Без, артистлар, үз арабызда аны бик яратып һәм хөрмәт итеп «Туташ» дип кенә атый идек.

*(Истәлек беренче мәртәбә «С. Гыйззәтуллина-Волжская турында истәлекләр». / Төз. Х.Гобәйдуллин.– Казан, 1982, (Б. 33–36) китабында басылган. Текст шуннан алынды.)*

***Риза Ишморат[1]***

## Рәхмәтем зур аңа

Театр кешеләр рухын бөеклеккә күтәрә, тетрәндерә, шатландыра, нурландыра, аңа бәхет бүләк итә торган иң көчле, тылсымлы сәнгать.

Илле елдан артык гомерем театрга багышланган. Хәтер йомгагын сүтеп, театр юлындагы беренче адымнарымны күздән кичерәм, уйланам...

Ниндидер көчләр, кемнәрдер мине җилкендереп, әйдәп, театр юлы белән алып киттеләр. Кемнәр алар? Кайдан башланды бу? Хәтерләргә тырышам: менә миңа 14–16 яшьләр. Мин – шәкерт. Уфада Госмания мәдрәсәсендә укыйм. Әдәби кичәләрдә яттан шигырьләр сөйлим. Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев һәм башкаларның шигырьләрен. Тукайның «Суык» дигән шигыреннән өзек – «Кичә генәк» – минем даими репертуарым. Тамашачылар яратып, алкышлар белән кабул итәләр. С.Рәмиевнең «Кеше» исемле шигырен дә яратып тыңлыйлар, кул чабалар.

---

[1] *Риза Ишморат (1903–*1995) – күренекле татар язучысы, драматург, ТАССР һәм РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе.